| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Брюшлинского сельского поселения Менделеевского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Бөрешле авыл җирлеге Советы |

| | |
|---|---|
| Р Е Ш Е Н И Е<br>2020 елның 29 июленнән | К А Р А Р<br>№170 |

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 129 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 1998 елның 31 июлендәге 146-ФЗ номерлы һәм 2000 елның 5 августындагы 117-ФЗ номерлы икенче өлеше нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 129 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турындагы гаризаны үз сайлавы буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган һәм тиешле салым буенча чираттагы салым чорының 1 нче числосыннан да иртәрәк булмаган вакытта закон көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварында барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын тарата.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында - http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatarstan.ru «Бөрешле авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырып бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Бөрешле авыл җирлеге
Советы Рәисе Л.А. Смирнова